**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәреш кертү турында

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы, 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы, 2018 елның 30 маендагы ПУ-397 номерлы, 2018 елның 26 июлендәге ПУ-541 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге ПУ-130 номерлы һәм 2019 елның 24 маендагы ПУ-294 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, аулау параметрларының III кисәгенә, 12 һәм 13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12. Язгы ау сезонында киек кошларны аулау, ауны аучылык ресурслары санын көйләү максатларында, фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, мәгариф эшчәнлеге алып бару максатларында оештыру очракларыннан кала, көн саен 10 сәгатьтән алып 17 сәгатькә кадәр тыела дип билгеләргә.

13. Әлеге параметрларның III кисәге 11 пункты дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән җәйге-көзге һәм көзге-кышкы ау сезоннары башыннан беренче һәм икенче атнаның сишәмбесе, чәршәмбесе һәм пәнҗешәмбесендә киек кошларны аулау, ауны аучылык ресурслары санын көйләү максатларында һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, мәгариф эшчәнлеге алып бару максатларында оештыру очракларыннан кала, тыела дип билгеләргә.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 24 июнь
№ ПУ-361